| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 14 декабре № 23/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 27 маендагы 9/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гавами тыңлауларнн (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 6 статьяда:**

**1 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Күрсәтелгән гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының вакытлы матбугат басмасында бастырып чыгарылырга, шул исәптән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.droganoye.tatarstan.ru) урнаштырылырга, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә урнаштырылырга тиеш (алга таба – Бердәм портал).

Бердәм порталда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халкына хәбәр итү максатларында гавами тыңлаулар билгеләү һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында мәгълүмат урнаштыру, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының шәхси кабинетын кулланып, әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакытта Бердәм порталның кире элемтә платформасының (алга таба – органның шәхси

кабинеты) тиешле бүлегендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы аппаратының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

**1.1 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләмәсен дә кертеп, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының вакытлы матбугат басмасында басылып чыга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.droganoye.tatarstan.ru) һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.».

**2) 7 статьяга** түбәндәге эчтәлекле **4.1 пунктын өстәргә:**

«4.1. Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча гавами тыңлауларга чыгарылган үз кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган кисәтүләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халкы тарафыннан, авторизациядән соң, Бердәм портал кулланып, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификациянең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә кертелә.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүматны һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлауларны үткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кертелгәндә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халкы шулай ук үз фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен таныклаучы төп документның реквизитлары, туу датасы һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында белешмәләр җибәрә.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров